КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 5 август г.Казань № 557

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2016 елларда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 сентябрь, 677 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә һәм 1 һәм 3 пунктларда «2015 – 2016 елларда» сүзләрен «2017 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 – 2016 елларда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибендә:

исемендә һәм 1 пунктта «2015 – 2016 елларда» сүзләрен «2017 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 – 2016 елларда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү тәртибендә:

исемендә һәм 1 пунктта «2015 – 2016 елларда» сүзләрен «2017 елда» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары хакында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 16 май, 349 нчы карары үз көчен югалткан дип санау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 сентябрь, 677 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин